ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«13» октября 2022 ел №917

**2023 елга Арча муниципаль районы коммуналь комплексы оешмаларының халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә түбәндәге тарифларны расларга:

-2023 елга торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча яллаучылар, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын һәм торак урыннар милекчеләрен сайлап алу турында гомуми җыелышта торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннарын яллаучыларга торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен (алга таба – халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре) 1 нче кушымта нигезендә;

- торак биналарның милекчеләре өчен капиталь ремонт өчен түләү күләмен, муниципаль торак фондының торак урыннарын торак урыннары наем шартнамәләре буенча яллаучылар өчен торак бинадан файдалануга тарифларны (наем өчен база ставкасы) 2 нче кушымта нигезендә;

2. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалы «Арск-информ» «Арча хәбәрләре» («Арский вестник») газетасында, рәсми хокукый мәгълүмат порталына (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М. Гатиятов

*Арча муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*«18» октября 2022 ел, № 917*
*карарына 1 нче кушымта*

**2023 елга торак урыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милечеләре һәм торак урыннарын карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга (алга таба – халыкка торак хезмәтләре)**

**ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**

| № | Түләү исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | 2023 елның I яртыеллыгына хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) | 2023 елның II яртыеллыгына хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 3,75 | 4,12 |
| 2. | Торак биналарны санитар карап тоту һәм санитар чистарту (ишегалды җыештыру) | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 4,37 | 4,37 |
| 3. | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 2,35 | 2,44 |
| 4. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 3,65 | 3,80 |
| 5. | Дератизация | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,31 | 0,31 |
| 6. | Йорт эчендәге газ белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,19 | 0,19 |
| 7. | Йорт эчендәге электр | аена торак | 0,55 | 0,55 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | челтәрләренә агымдагы ремонт | урынының гомуми мәйданы кв.м | | |
| 8. | Йорт эчендәге үзәк җылыту системасына агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,11 | 0,11 |
| 9. | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә (югары насос станцияләре белән җиһазландырылмаган су белән тәэмин итү һәм канализация челтәрләре) агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 1,80 | 1,80 |
| 10. | Йорт эчендәге санитар-техник челтәрләргә (югары насос станцияләре белән җиһазландырылган су белән тәэмин итү һәм канализация челтәрләре) агымдагы ремонт | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 2,82 | 2,82 |
| 11. | Домофон | аена фатир | 1,00 | 1,05 |
| 12. | Төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,85 | 0,94 |
| 13. | Җилләтү юлларына техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,85 | 0,94 |
| 14. | Телевидениене күмәк кабул итү системаларын техник яктан тәэмин итү һәм ремонтлау | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | 0,43 | 0,43 |

Башкарма комитетның инфраструктура
үсеше бүлегенең ТКХ, энергетика
һәм элемтә секторы мөдире А.Р.Шәйхетдинов

*Арча муниципаль районы*
*башкарма комитетының*
*«13» октябрь 2022 ел, № 917*
*карарына 2 нче кушымта*

**Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучыларга торак урыныннан файдаланган өчен (наем өчен)**
**БАЗА СТАВКАСЫ**

| Түләү исеме | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге | 2023 елга хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|
| Наем өчен база ставкасы | аена торак урынының гомуми мәйданы кв.м | Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 20 декабрендәге 1140 номерлы карары белән расланган торак урыннан файдаланган өчен түләү (наемга түләү), муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча яллаучылар өчен түләү күләмен исәпләү методикасы нигезендә |

Башкарма комитетның инфраструктура
үсеше бүлегенең ТКХ, энергетика
һәм элемтә секторы мөдире А.Р.Шәйхетдинов